ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

7 август, 2024 ел № 35/8

Муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында

«Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 24 июнендәге 454 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Расларга:

1) муниципаль гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә;

2) муниципаль мәктәпкә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә;

3) муниципаль өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәне 3 нче кушымта нигезендә;

4) муниципаль мәгариф оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең гомумтармак вазыйфалары, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы нигезләмәне 4 нче кушымта нигезендә.

2. Көчен югалткан дип танырга:

1) Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәренең муниципаль белем бирү оешмалары һәм аерым муниципаль оешмалары җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 10 августындагы 26/8 номерлы Карарының 1 пунктын, «Челнинские известия» газетасының 2018 елның 5 сентябрендәге 63, 7 сентябрендәге 64, «Шәһри Чаллы» газетасының 2018 елның

12 сентябрендәге 65 саннарында басылган, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 10.09.2018 урнаштырылган.

2) Шәһәр Советының «Яшьләр эшләре буенча муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында нигезнамәләрне раслау һәм Шәһәр Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 8 ноябрендәге 27/10 номерлы Карарының 5 пунктын, «Челнинские известия» газетасының 2018 елның 23 ноябрендәге 85, «Шәһри Чаллы» газетасының 2018 елның 23 ноябрендәге 85 саннарында басылган, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 15.11.2018 урнаштырылган;

3) Шәһәр Советының «Шәһәр Советының муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре хезмәтенә түләү турында аерым Карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 23 маендагы 31/6 номерлы Карарының 3 пунктын, «Челнинские известия» газетасының 2019 елның 31 маендагы 38, «Шәһри Чаллы» газетасының 2019 елның 5 июнендәге 39 саннарында басылган, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 31.05.2019 урнаштырылган;

4) Шәһәр Советының ««Шәһәр Советының 2018 елның 10 августындагы «Яр Чаллы шәһәренең муниципаль белем бирү оешмалары һәм аерым муниципаль оешмалары җитәкчеләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында» 26/8 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында»» 2019 елның 6 декабрендәге 34/7 номерлы Карарының 1 пунктын, «Челнинские известия» газетасының 2019 елның 11 декабрендәге 91, «Шәһри Чаллы» газетасының 2019 елның 13 декабрендәге 92 саннарында басылган, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 12.12.2019 урнаштырылган;

5) Шәһәр Советының «Шәһәр Советының муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында аерым Карарларына үзгәрешләр кертү хакында»» 2020 елның 11 августындагы 41/8 номерлы Карарының 1 пунктын, «Челнинские известия» газетасының 2020 елның 12 августындагы 58, «Шәһри Чаллы» газетасының 2020 елның 12 августындагы 58 саннарында басылган, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 14.08.2020 урнаштырылган;

6) Шәһәр Советының «Шәһәр Советының муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында аерым Карарларына үзгәрешләр кертү хакында»» 2021 елның 27 декабрендәге 11/7 номерлы Карарының 8 пунктын, «Челнинские известия» газетасының 2022 елның 1 гыйнварындагы 3, «Шәһри Чаллы» газетасының 2022 елның 1 гыйнварындагы 3 саннарында басылган, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 14.01.2022 урнаштырылган;

7) Шәһәр Советының «Шәһәр Советының муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында аерым Карарларына үзгәрешләр кертү хакында»» 2022 елның 22 августындагы 16/6 номерлы Карарының 1 пунктын, «Челнинские известия» газетасының 2022 елның 26 августындагы 62, «Шәһри Чаллы» газетасының 2022 елның 26 августындагы 62 саннарында басылган, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 31.08.2022 урнаштырылган;

8) Шәһәр Советының «Шәһәр Советының муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү өлкәсендәге аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 8 декабрендәге 18/7 номерлы Карарының 1 пунктын,

«Челнинские известия» газетасының 2022 елның 21 декабрендәге 93, «Шәһри Чаллы» газетасының 2022 елның 21 декабрендәге саннарында басылган, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 21.12.2022 урнаштырылган;

9) Шәһәр Советының ««Шәһәр Советының 2018 елның 10 августындагы «Яр Чаллы шәһәренең муниципаль белем бирү оешмалары һәм аерым муниципаль оешмалары җитәкчеләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында» 26/8 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында»» 2023 елның 25 октябрендәге 26/8 номерлы Карарының 1 пунктын, «Челнинские известия» газетасының 2023 елның 1 ноябрендәге 79, «Шәһри Чаллы» газетасының 2023 елның 1 ноябрендәге 79 саннарында басылган, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 08.11.2023 урнаштырылган;

10) Шәһәр Советының «Шәһәр Советының муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү өлкәсендәге аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 6 декабрендәге 28/7 номерлы Карарының 2 пунктын, «Челнинские известия» газетасының 2023 елның 8 декабрендәге 90, «Шәһри Чаллы» газетасының 2023 елның 8 декабрендәге 90 саннарында басылган, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 19.12.2023 урнаштырылган;

11) Шәһәр Советының «Шәһәр Советының 2018 елның 10 августындагы «Яр Чаллы шәһәренең муниципаль белем бирү оешмалары һәм аерым муниципаль оешмалары җитәкчеләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында» 26/8 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында»» 2024 елның 2 маендагы 33/6 номерлы Карарының 1 пунктын, «Челнинские известия» газетасының 2024 елның 8 маендагы 31, «Шәһри Чаллы» газетасының 2024 елның 8 маендагы 31 саннарында басылган, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 17.05.2024 урнаштырылган.

3.Әлеге Карар рәсми басылган көненнән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 июленнән соң хасил булган хокукый мөнәсәбәтләр өчен гамәлдә дип билгеләргә.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев